**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары**

Әгерҗе авылы № 176-81 19 май 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Кушымта итеп бирелгән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын 04.04.2014 № 86, 15.08.2014 № 100, 11.09.2017 № 64-29, 15.02.2019 № 129-61 карарлар редакциясендә) хупларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2012 елның 29.10 50 номерлы карары 04.04.2014 № 86, 15.08.2014 № 100, 11.09.2017 № 64-29, 15.02.2019 № 129-61) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты – 2020 елның 28маеннан 2020 елның 30июненә кадәр;

- үткәрүурыны– Әгерҗе авылы, Г.Әхмәтова урамы, 14а йорт;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2020елның 30 июненә кадәр- Әгерҗе авылы, Г.Әхмәтова урамы, 14а йорт, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе выл җирлеге Башкарма комитетына (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Хәсәнов Назыйф Нилович – Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы;

- Тимиряев Валерий Демьянович –Әгерҗе авыл җирлеге Советының № 2 округ депутаты;

- Фәттәхов Ирек Абугалиевич – авыл җирлеге Советының № 6 округ депутаты;

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2012 елның 29.10 50 номерлы карары (04.04.2014 № 86,

15.08.2014 № 100, 11.09.2017 № 64-29, 15.02.2019 № 129-61) белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, 2020 елның 25 маеннан да соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

АГЕРЗИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1602002575 КПП 164301001

Рәис: Н.Н.Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл Советының
2020 елның 19 маендагы 176-81
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары**

Әгерҗе авылы №___ __ __________ 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 29.10. 50 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2014 елның 04.04. 86 номерлы, 2014 елның 15.08. 100 номерлы, 2017 елның 11.09. 64-29 номерлы, 2019 елның 15.02. 129-61 номерлы карарлар редакциясендә)

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 29.10. 50 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (2014 елның 04.04. 86 номерлы, 2014 елның 15.08. 100 номерлы, 2017 елның 11.09. 64-29 номерлы, 2019 елның 15.02. 129-61 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктның өченче абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1.3. пунктның унынчы абзацында «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.7.пунктта «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 2.10.3 – 2.11.2, 2.11.4 пунктларда «каты көнкүреш калдыклары» сүзләрен «каты коммуналь калдыклар» сүзләренә, «ТБО» аббревиатурасын «ТКО» аббревиатурасына алмаштырырга.

1.5. Түбәндәге эчтәлекле 2.11.7 пункт белән тулыландырырга:

«2.11.7. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар

туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.